Нигъмәтуллина, З. Парижларны яулаган рәссам / З. Нигъмәтуллина // Сөембикә. – 2023. – №5. – Б. 64





# ПАРИЖЛАРНЫ ЯУЛАГАН РӘССАМ

Яз җитүгә Чаллы рәссамы Галина Недовизий киндерләрендә чәчәк сурәтләре арта: сиреньнәр, чия, алмагач, шомырт чәчәкләре... «Май ае чәчкәләрен киндерләргә күчерергә яратам, үзем дә майда туган кыз бит мин!» – ди ул.

Галина Недовизий 1956 елның 5 маенда Чиләбе өлкәсенең Коркино шәһәрендә дөньяга килгән. «Әти-әниебез укытучылар иде, ә менә без өчебез дә сәнгать өлкәсен сайладык: энем Владимир – дизайнер, сеңлем Ирина – рәссам-модельер. Балалар сынлы сәнгать мәктәбендә укымадым, әмма хыялыма ураү юллар аша да килмәдем. Башта Магнитогорск дәүләт педагогика институтының сынлы сәнгать-графика факультетын тәмамладым һәм дүрт ел ярым Новосибирск дәүләт педагогика институтында укыттым. Аннары өч ел Троицкидагы балалар сынлы сәнгать мәктәбендә белем бирдем. 1986–1993 елларда Чаллы педагогика институтының сынлы сәнгать-графика факультетында укытучы булып эшләдем. Һәр рәссам үз осталыгын камилләштерергә омтыла, мин дә 1990–1991 елларда СССР Рәссамнар берлегенең Горячий Ключтагы иҗат йортында һәм Вышний Волочектагы «Академическая» дачасында иҗат командировкаларында булып, гыйлемнәремне арттырдым», – дип искә төшерә рәссам.

Галина ханым 1993 елдан Россия һәм Татарстан Рәссамнар берлеге сафларында. Шәхси күргәзмәләрен ачкач, аның әсәрләрен үз итүчеләр саны арткан. 1995 елдан башлап Галина ханым Чаллы Сынлы сәнгать фонды остаханәсендә иҗат итә. Кайсы иҗатчының Парижны күрәсе килмәс?! «Парижны күрсәң, үлсәң дә була!» дигән канатлы сүзләр юкка гына яңгырамый шул... Менә Галина Недовизий да үз алдына шундый хыял-максат куйган. Өстәвенә, аның картиналары 1993 елда ук Франциядә, ЮНЕСКО оештырган «Яшь шәһәрләр мәдәнияте» халыкара конференциясе кысаларында узган «Ике автоград» күргәзмәсендә экспозицияләнгән. «1995 елда мин инде Париж урамнары буйлап атладым! – дип искә ала оста. – Андагы Халыкара сәнгать үзәге чакыруы буенча без күп картиналар яздык. Франциягә мин берничә тапкыр бардым әле, 1997 елда Парижның «Эверарт» галереясында шәхси күргәзмәм дә ачылды. Иҗатымда – натюрмортлар, портретлар. Ә пейзажларым арасында Франция күренешләре дә шактый... 2016 елда Һиндстанда, Делида үткән Халыкара мәдәният фестивале дә бик истә калды.

Гомерем буе туган җиребез табигатен, урманнарыбызны, төрле бакча-паркларыбызны да бик теләп тасвирлыйм. Һәм нинди күренешне генә сурәтләсәм дә, һәр әсәремнең сюжеты яктылык белән бәйле!»

Галина Недовизийнең илһамлы иҗаты Россия һәм Татарстан Республикасы Рәссамнар берлекләренең Мактау грамоталары белән зурланган. Чаллының «Ел рәссамы–2018» конкурсының «Сынлы сәнгать» номинациясендә дә җиңеп чыккан.

Аның әсәрләре Г. М. Хәкимова исемендәге Чаллы картина галереясында, Татарстан Республикасы дәүләт сынлы сәнгать музее фондларында, Мәскәү шәхси музейларының берсендә һәм Россия, Болгария, Словения, Франция, АКШ, Италия, Төркия, Германия, Швециядәге шәхси тупланмаларда саклана.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА













«Май кичә» эше Г. М. Хәкимова исемендәге Яр Чаллы картина галереясы фондыннан алынды.

## ГАЛИНА НЕДОВИЗИЙ